| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br><br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br><br>ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| ПОСТАНОВЛЕНИЕ | с. Тюлячи | КАРАР |
|---|---|---|
| «25» января 2021 | | № 17 |

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычлар булу (булмау) турында салым түләүчеләргә мәгълүмат бирү эшен оештыру хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 30 декабрендәге 16-54/16211 номерлы хатын карап, Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсенең һәм Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2021-2023 елларга мәгълүмати хезмәттәшлек буенча Килешүне гамәлгә ашыру максатларында, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының структур бүлекчәләренә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетына түләүләр буенча бурычлар булу (булмау) турында салым түләүчеләргә мәгълүмат бирү эшен оештырырга.

2. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш һәм инвестиция эшчәнлеге бүлегенә 2020 елның 27 гыйнварыннан да соңга калмыйча дәүләт хезмәтләре күрсәткәндә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 елның 7 августындагы 674 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан дәүләт вазыйфаларын башкарганда ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек Тәртибе нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең, мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне оештыруга гариза җибәрергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары - территориаль үсеш һәм инвестиция эшчәнлеге бүлеге башлыгы И.Ә. Миңнегуловка йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин